**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАДРЯКОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МЕНЗЕЛИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНЗӘЛӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КАДРӘК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**423715, Республика Татарстан Мензелинский район, с.Кадряково, ул.Кирова, 31**

**423725, Татарстан Республикасы, Минзәлә районы Кадрәк авылы, Киров урамы, 31**

телефон: (85555) 2-61-24 E-mail Kadr.Mnz@tatar.ru

КАРАР

№ 20 04 июнь 2018 ел

**«2018-2023 елларга Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Кадрәк авыл җирлегенең транспорт инфраструктурасы системасын комплексны үстерү программасын һәм перспектива белән 2030 елга кадәр раслау турында»**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2014 елның 29 декабрендәге 456-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Җирлекләрнең, шәһәр округларының транспорт инфраструктурасы системаларын комплексны үстерү программаларына таләпләрне раслау турында» 2015 елның 25 декабрендәге 1440 номерлы карары, Татарстан Республикасы Президенты күрсәтмәсе нигезендә «Муниципаль берәмлекләрнең транспорт инфраструктурасы системаларын комплексны үстерү программасын эшләү турында» 2016 елның 6 июнендәге 326661-МР номерлы Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Кадрәк авыл җирлеге Башкарма комитеты

КАРАР ЧЫГАРА:

1. Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Кадрәк авыл җирлеге транспорт инфраструктурасы системасын 2018-2023 еллар чорына һәм 2030 елга кадәр перспектива белән комплексны үстерү программасын расларга.

2. Әлеге карарны җирлекнең рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының «Интернет» челтәрендәге рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Кадрәк авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе: Х.Х.Нәбиуллин